СОВЕТ
АПАЗОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д. 18, с.Апазово,
Арский муниципальный район, 422006

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АПАЗ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 18 йорт, Апаз авылы,
Арча муниципаль районы, 422006

Тел. (84366)94-2-37, факс (84366)94-2-37. E-mail: Apaz.Ars@tatar.ru

**Апаз авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**“18” ноябрь 2019 ел** **№ 170**

**Апаз авыл җирлеге Советының 2017 елның 27 октябрендәге 85 номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенең 31 бүлеге, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Апаз авыл җирлеге Уставы нигезендә Апаз авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Апаз авыл җирлеге Советының 2017 елның 27 октябрендәге 85 номерлы «Җир салымы турында» карарына (Апаз авыл җирлеге Советының 2019 елның 21 августындагы 158 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1) 3 пунктның 3.1.1 пунктындагы беренче абзацында «автомобиль юллары» сүзләреннән соң «, әлеге карарның 2 пунктындагы 2.1 пунктчасында күрсәтелгәннәрдән тыш, " сүзләрен өстәргә»;
2) 4 пунктның дүртенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарның 1 пунктындагы 2 пунктчасының гамәлдә булуы 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
3. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында рәсми басылып чыккан көннән бер ай үткәннән соң үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль мәсьәләләр буенча даими эшләүче комиссиягә йөкләргә.

Апаз авыл җирлеге башлыгы Р. Ш. Садыйков